# Чишмә башы

1 нче сан
Ноябрь , 2024

**Арча муниципаль районы
МБМББУ «Хәсәншәех балалар бакчасы”
редакциясе**





Безнең адрес: Татарстан Республикасы,
Арча районы, Хәсәншәех авылы,
Татарстан урамы, 52 нче А йорт

***Бу санда:***

- ***Бакчабыз тарихы***
- ***Бездә күңелле***
- ***Туган телем сагында***

***Баш мөхәррир- бакча мөдире
Әхмәдуллина Гүзәл Сәйдәш кызы
Мөхәррир урынбасарлары:
Тәрбиячеләр-
Хисамиева Ләйсән Илсур кызы
Әхмәдуллина Ләлә Зиннур кызы
Вәлиева Рәмлә Камил кызы.***




# Бакчабыз тарихы

**Безнең авылда сугыш вакытында ук балалар бакчасы булган. Хамматов Фирдүс абыйның әнисе Голирам апа да хәтерли ул бакчаны. “Бакча янында 3 тополь үсә иде, чыпта суга,җыя торга әртил иде анда “ – дип сөйли ул.**

**1986 нчы елның 1 нче июлендә Хәсәншәех авылында иске клуб урынында заманча уңайлыклар белән 40 балага исәпләнгән балалар бакчасы ачыла. Бакчаның беренче мөдире Солтанова Энҗе апа була. Ул сөйләгәннәрдән, без бакчаның күп еллык тарихыннан кызыклы истәлекләрне белдек.Бакча совхоз җитәкчелеге көче, Ахметов Готыф абый тырышлыгы белән салына. Авыл осталары үзләре бурасын бурап, үзләре күтәрәләр. Ул вакытта прораб Закиров Иллдус абый була. Ул вакыттагы партком секретаре Саляхов Хөрмәтулла абый, Гали абыйлар да һәрвакыт төпле киңәшләрен биреп торалар.**

**Шул бакчаның котельные урынында Казан шәһәре меры Камил Исхаковның әнисе Илһамия апаның туган нигезе булган.Аның Рәшит исемле малае авылга кайтып,шул урыннарны фотога төшереп йөргән, балалар бакчасына материаль ярдәм күрсәткән.**

**2004 нче елда авылдашыбыз Авыл хуҗалыгы министры Ахметов Марат абый ярдәме белән бакчага капиталь ремонт ясалган яшел калайдан түбә ябылган, агач стеналар тышкы яктан кызыл кирпеч белән тышланган, капка коймалар алыштырылган, эчке якка Ахметов Мансур абый ярдәме белән уңайлы техника һәм мебель алынган. Бу бакчада Газизова Зөлфирә, Хазиахметова Лида, Солтанова Энҗе , Рамазанова Сиринә , Саляхова Тәнзилә апалар озак еллар эшләп лаеклы ялга чыктылар.**

**2017 нче елда федераль программа нигезендә, Ахметов Марат абый ярдәме белән авылыбызда өр-яңа балалар бакчасы төзелде.Ул 50 балага исәпләнгән. Бакча мөдире Ахмадуллина Гүзәл Сәйдәш кызы. Материаль шартларның яхшыруы безнең өчен яңача эшли башларга, яңа күрсәткечләргә омтылырга этәргеч бирде. Безнең балалар бакчасында балалар организмының функциональ мөмкинлекләрен арттыру, физик сыйфатларны һәм сәләтләрне үстерү өчен шартлар тудырылган.**

**Бакчабызда яңа технологияләр кулланып,белем һәм тәрбия бирү, балаларны ике телдә камил сөйләшергә өйрәтү, тиешле дәрәҗәдә мәктәпкә әзерләүне тормышка ашыру бурычы куелган.**

**Яңа бакчада поварыбыз Ахметгалиева Фәния апа, тәрбияче Валиева Рузалия апалар нәтиҗәле хезмәт белән лаеклы ялга чыктылар.**

***Әхмәдуллина Г.С.***

# Бездә күңелле “Әниләр көне”

**Әнием кадерлем!**

**Назлы караш әни карашында**
**Яратып тибә әни йөрәге**
**Бернинди дә бәхет,шатлыкларга**
**Алыштырып булмый әнине.**

**Әни! Һәркем өчен иң изге,иң кадерле кеше.Әниләр- сез өйләребезнең яме. Әни,әнием!Нинди матур сүзләр.Кадерләп әйтәбез без аларны.Безне бу дөньяга тудырган, яраткан,безнең уңышларыбызга шатланган авыр чакта гел ярдәмгә килеп яшәгән әниебезгә шулай дип дәшәбез.**

**Без дә узебезнең матур, якты,җылы бакчабызда әниләр көненә бәйрәм уздырдык.Балаларның чыгышларын әниләр куанып,шатланып горурланып карап утырдылар.Әниләр үзләре дә уеннарда катнашып бәйрәмне тагын да ямьләндереп җибәрделәр.Фахрутдинова Язгөл әнисе белән җырлап бик матур чыгыш ясадылар.**

**Бәйрәмегез белән, кадерле Әниләр! Саулык-сәламәтлек, гаилә шатлыклары, елларның иминлеге, күңелләрнең тынычлыгы — барысы да — Сезгә! Бүгенге бәйрәм улларыгыз, кызларыгыз өчен сөенү хисләрен тагын да арттырсын. Кояшны җылырак, җилләрне ягымлырак, көннәрне аязрак, күкләрне зәңгәррәк итсен!**

**Әхмәдуллина Л.З.**





# Туган телем сагында



Балаларның сөйләм телен үстерү

**Балалар бакчасында балаларның киләчәгенә юл салына.Баланы кече яшьтән үк туган телен яратырга, дөрес, матур,аңлаешлы итеп сөйләшергә өйрәтү мөһим.Бүгенге көндә балаларның сөйләм теле тиешле дәрәҗәдә түгел дип саныйм, чөнки алар сөйләм вакытында сүзләрне йота, русча сүзләр кулланып сөйләшә, күп авазларны әйтә алмый. Гаиләдә дә бала белән аралашу җитми. Бу максаттан, бакчабызда санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар , татар халык уеннары ярдәмгә килә.Уеннар вакытында балаларның сөйләм теле формалаша. Без балалар белән " Кәрия-Зәкәрия", Чума үрдәк, чума каз", " Утыр, утыр Мәликә", " Гөлбану", " Түбәтәй" уеннарын яратып уйныйбыз.**

**Хисамиева Л. И.**

**Әгәр баланың сөйләмендә тайпылышлар була икән, андыйлар гадәттә,үз эченә бикләнүчән була. Хәтта бу кимчелекләр баланың акыл үсешенә зыян салырга, психикасы бозылырга мөмкин. Укуда да артта калуы ихтимал. Сабыйның сөйләмендәге кимчелекләргә вактында игътибар итәргә кирәк. Ул кимчелекләрне төзәтү өстендә 3-4 яшьтән шөгыльләнә башламасаң, вакыт үткән саен кыенрак булачак.Кайбер авазларны әйтә алмау,бозып әйтү, басымнарны ялгыштыру, авазларны йоту, иҗекләрне бутау – болар барысы да балалар сөйләмендәге төп кимчелекләр булып тора. Бала белән өйдә дә шөгыльләнергә кирәк.**

**Вәлиева Р.К.**



